**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Макуловского сельского поселения Верхнеуслонского муниципального района**

422582, с. Русское Макулово, ул. Центральная, д.110
тел. (8 - 84379) 34-4-95, 34-4-74 факс: (8 - 84379) 34-4-95

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Югары Ослан муниципаль районнарның Макыл авыл жирлеге**

СОВЕТЫ

422582, Макыл авылы, Узәк ур., 110 нчы йорт
тел. (8 - 84379) 34-4-95, 34-4-74 факс: (8 - 84379) 34-4-95

# КАРАР

2015 елның 24 апреле № 57-281

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Нуруллин мәгълүматын тыңлап Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советы билгеләп үткәнчә, гамәлдәге законнар үзгәрүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнде, ул җирлек Советы тарафыннан хупланды, Җирлек җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерелде һәм җирлек халкы белән гавами тыңлауларда фикер алышуның барлык кирәкле процедураларын узды.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары һәм 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19, 97-99 статьялары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставының 19, 97-99 статьялары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1.Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен расларга.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Нуруллин

Макыл авыл җирлеге
Советының 24.04.2015 ел,
№ 57-281 карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. Уставның 7 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору, җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап төзү һәм раслау;

2) җирлекнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару;

3) җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

5) җирлек халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

6) ял итүне оештыру һәм җирлектә яшәүчеләрне мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

7) җирлек территориясендә физик культураны һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

8) җирлекнең архив фондларын булдыру;

9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, шул исәптән алар урнашкан биналарны (торак йортларны да кертеп), корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен карап тоту таләпләрен, тиешле биналарның һәм корылмаларның тышкы кыяфәтенә һәм коймаларын, төзекләндерү һәм аларны үтәү буенча эшләр исемлеген раслау; биналар (аларда биналар) милекчеләренең һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерүдә катнашу тәртибен билгеләү; җирлек территориясен территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнар исемнәре һәм йортларның номерлары булган күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тотуны да кертеп);

10) адрес объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, аннулировать итү, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, аннулировать итү, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

11) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;

12) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

13) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

14) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыюны һәм алып китүне оештыру;

15) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

2.Уставның 7.1 статьясын түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

13) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын күрү;

3. Уставның 11 статьясындагы 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Җирле референдумны әзерләү һәм уздыру тәртибе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон һәм «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына;

4. Уставның 29 статьясындагы 6 пунктының 1 пунктчасын төшереп калдырырга;

5. Уставның 29 статьясындагы 6 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләреннән тыш), әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса һәм федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса»;

6. Уставның 32 статьясының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек советы компетенциясендә:

1) Җирлек уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) Җирлек территориясендә гомуммәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;

3) Җирлек бюджетын һәм аның үтәлеше турында хисап раслау;

4) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм юкка чыгару, аларны түләү буенча ташламалар бирү;

5) Халык санын үстерү планнарын һәм программаларын кабул итү, аларның үтәлеше турындагы хисапларны раслау;

6) җирлекләрнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын раслау.

7) Чикләрне үзгәртү, Җирлекне үзгәртү турындагы инициативаны күрсәтү;

8) Җирлек Советы депутатларын сайлауларны билгеләү; җирлек Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау округлары схемасын раслау;

9) җирле референдумны билгеләү;

10) Җирлек башлыгын сайлау;

11) авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан муниципаль район Советына Җирлек вәкилен сайлау;

12) җирлек җирле үзидарә органнарының структурасын раслау, җирле үзидарә органнарының һәркайсының эчке структурасын һәм аларның штат расписаниесен раслау;

13) Җирлек сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую;

14) җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, җирлек Советы депутаты чакыртып алу буенча тавыш бирү билгеләү;

15) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

16) Җирлек муниципаль милкендәге мөлкәткә идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү, аны читләштерү Җирлек Советы тарафыннан килештереп яисә расланганнан соң башкарыла торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

17) җирлекнең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

18) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәүне тикшереп тору;

19) Җирлек тарафыннан заем чараларын җәлеп итү тәртибен раслау, гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чыгару тәртибен билгеләү.

20) җирлек территориясендә торак пунктларның урамнарын һәм башка өлешләрен атамалау һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

21) муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү;

22) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына җирлек бюджетыннан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

23) автономияле коммерциягә карамаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциягә карамаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү; авыллар;

24) җирлек Советы Регламентын һәм үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар кабул итү;

25) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнарын алып баруга кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав тарафыннан Поселение Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр».

7. Уставның 45 статьясындагы 1 пунктының 11.1 пунктчасын төшереп калдырырга;

8.Уставның 45 статьясының 4 пунктын төшереп калдырырга;

9. 50 статьяның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы - җирлек советы, ә икенче яртысы - Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә».

10. Уставның 75 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару, халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр аларның карары белән башкасы билгеләнмәгән булса, җирлек Башлыгы имза салган көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Салымнар һәм җыемнар турында Җирлекнең хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Җирлек Уставын кабул итү яисә әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карарлары федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенең, җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актлар белән башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль хокукый актлар алар рәсми басылып чыкканнан соң йә халыкка җиткергәннән соң үз көченә керә.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары: исеме, аңа имза салу датасы (Җирлек Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен - шулай ук аны Җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актны имзалаган вазыйфаи зат исеме булырга тиеш.

5. Җирлекнең бюджет турындагы карары, аның үтәлеше турындагы хисап, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турындагы карарлар кабул ителгән көннән алып җиде көн эчендә рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш. Җирлек Советы регламенты, Җирлек Советы, Җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларны кабул иткән көннән алып җиде көн эчендә халыкка җиткерелергә тиеш.

6. Шулай ук җирле референдумны билгеләү турында, чикләрне үзгәртү, Җирлекне үзгәртеп кору, Җирлек башлыгын сайлау мәсьәләсе буенча норматив булмаган хокукый актлар һәм законнар нигезендә башка актлар һичшиксез рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

7. Законнар яисә әлеге Устав нигезендә рәсми басылып чыгуы мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар аларны бастырган органнар яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары карары буенча бастырып чыгарылырга мөмкин.

8. Басылып чыкканда, яки халыкка җиткергәндә муниципаль хокукый акт реквизитлары күрсәтелә.

9. Муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару «Волжская новь» район газетасында хокукый акт текстын бастырып чыгару яисә хокукый акт текстын Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Шулай ук муниципаль норматив хокукый актлар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин»

19. Уставның 75 статьясындагы 10 пунктында «Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итү, урнаштыру» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. Җирле үзидарә органнарының, муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җирлек Башлыгы тарафыннан җибәрелә».

11. Уставның 85 статьясының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлдәге законнар белән хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук җирле үзидарә органнарының әлеге Уставның 7 статьясындагы 3 пунктында каралган тәртиптә аларга тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) Югары Ослан муниципаль районы Советы карарлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятие һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән хәл итү хокукы бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

12. Уставның 91 статьясының 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләренә;

җирлек салым сәясәтенең төп юнәлешләре һәм бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре;

Россия Федерациясе таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре;

җирлекнең социаль-икътисадый үсешен фаразлау;

озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

муниципаль программаларда (муниципаль программалар проектларында, күрсәтелгән программалар проектларында) җирлек».

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Нуруллин